СОВЕТ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**Карар** **Решение**

№ 11-6 от « 26 » марта 2021 г.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районының
административ комиссиясен төзү турында

«Муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына административ комиссияләр төзү һәм аларның эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2005 нче елның 30 нчы декабрендәге 144-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитетын административ комиссия төзү өчен вәкаләтле орган итеп билгеләргә.

2. Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетына:

административ комиссия төзергә;

административ комиссиянең составын расларга;

административ комиссиянең эш регламентын расларга.

3. Әлеге карар Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район башлыгы урынбасары, муниципаль район Советы Рәисе урынбасары Р. Р. Сәмигуллинга йөкләргә.

Район Башлыгы,
муниципаль район
Советы рәисе А.П.Иванов

000022